Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге
Нырсуар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

18 октябрь, 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлегенең Нырсуар торак пунктында 2024 елның 18 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 67 (алтмыш җиде).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 34 (утыз дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 34 (утыз дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Нырсуар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1800 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, күп балалары булган күп балалы гаиләләрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов